КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 22 июль г.Казань № 712

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Гарантия фонды» коммерциягә карамаган оешмасы чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 9 июнь, 438 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы Гарантия фонды» коммерциягә карамаган оешмасы чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Гарантия фонды» коммерциягә карамаган оешмасы чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 9 июнь, 438 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 29 сентябрь, 875 нче; 2019 ел, 15 май, 397 нче; 2021 ел, 19 апрель, 256 нчы; 2021 ел, 5 июль, 544 нче; 2022 ел, 1 март, 187 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасы Гарантия фонды» коммерциягә карамаган оешмасы чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә (алга таба – Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

11.1 пунктның унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Фондның, Фонд белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) Министрлык тарафыннан аларга карата субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә ризалыгы (чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә субсидия алганда);»;

14 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Министрлык Фондның субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра, дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.»;

18 пунктта «максатчан һәм» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Тәртипнең 4 пунктындагы өченче абзацының, 6 пунктындагы дүртенче абзацының гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин